# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

**24.11.2020 ел** **№ 3**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2020 елның 24 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

- Урал торак пункты, Урал урамы, 10В йорт адресы буенча 50 урынга исәпләнгән күпфункцияле үзәк бинасы каршындагы мәйданчыкка асфальт салу (асфальт сатып алу, нигез әзерләү, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 140 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 75 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
халык җыенында катнашучы 75 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пунктында халык җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип исәпләргә.

2. "2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Урал торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 400,00 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Урал торак пунктындагы Урал урамы, 10В йорт адресы буенча урнашкан 50 урынга исәпләнгән күпфункцияле үзәк бинасы каршындагы мәйданчыкка асфальт салу (асфальт сатып алу, нигез әзерләү, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү) - карарын кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми

сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев